**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 2** **«20» ноябрь 2020 ел**

2021 елда Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Карамалы авыл җирлеге составына керүче,
Октябрь-Бүләк авылында
үзара салым кертү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Октябрь - Бүләк авылында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2021 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, гражданнарның аерым категорияләре өчен: 2 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәкләр, күп балалы гаиләләр, өчен түләү күләмен 50 (илле) процентка киметеп, Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Октябрь- Бүләк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге оешмаларга юнәлдерергә:

- Октябрь-Бүләк торак пункты Центральная урамы буенча балалар уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча түләү);
- Октябрь- Бүләк торак пунктында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Октябрь- Бүләк торак пунктында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту);
- Октябрь-Бүләк торак пунктында спорт инвентаре сатып алу (теннис өстәле).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль

берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Октябрь-Бүләк авылы, Үзәк урам, 8 нче йорт.

Гражданнар җыенында
рәислек итүче,
Карамалы авыл җирлеге Башлыгы А.Р. Ногманов